РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№________** **«___»___________2018 г.**

2018 елның 16 июнендә Теләче авылында ир-атлар арасында
билбау көрәше буенча Дөнья Чемпионатына әзерлек һәм уздыру буенча
оештыру комитеты турында

Халыкара билбау көрәше федерациясе президентының 2018 елның 24 апрелендәге 34 номерлы хатын карап, спорт төрен популярлаштыру максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2018 елның 16 июнендә Теләче авылында ир-атлар арасында билбау көрәше буенча Дөнья Чемпионатының беренчел көрәшләрен оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга.

2. Теләче авылында 2018 елның 16 июнендә ирләр арасында билбау көрәше буенча Дөнья Чемпионатына әзерек һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба текст буенча - Оештыру комитеты) төзергә һәм аның составын кушымта нигезендә расларга.

3.Оештыру комитетына ун көн эчендә Теләче муниципаль районы Башлыгына 2018 елның 16 июнендә Теләче авылында ир-атлар арасында билбау көрәше буенча дөнья чемпионатына әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планын әзерләргә һәм раслауга тапшырырга.

4. 2018 елның 16 июнендә Теләче авылында «Батыр»универсаль спорт залын ир-атлар арасында билбау көрәше буенча Дөнья Чемпионатының беренчел ярышларын уздыру урыны итеп билгеләргә.

5. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына:

оештыру комитеты эшен тәэмин итәргә;

гамәлдәге законнар нигезендә, ир-атлар арасында билбау көрәше буенча Дөнья Чемпионатына әзерлек һәм аны үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслау чыганакларын билгеләргә.

6. "Татмедиа" АҖ филиалы «Теләче информ» мәгълүмат агентлыгына 2018 елның 16 июнендә Теләче авылында ир-атлар арасында билбау көрәше буенча Дөнья

Чемпионатының башлангыч көрәшләрен киң яктыртуны тәэмин итәргә, әлеге вакыйгаларга багышланган материаллар, телевизион тапшырулар һәм радиотапшырулар әзерләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

И. Ф. Зарипов

Теләче муниципаль
районы Башлыгының
«__» _______ 2018 ел № ___ карарына
кушымта

Теләче авылында 2018 елның 16 июнендә ирләр арасында билбау көрәше буенча Дөнья Чемпионатына әзерек һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы

Оештыру комитеты рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Зарипов И. Ф. | - | Теләче муниципаль районы Башлыгы; |

Оештыру комитеты рәисе урынбасарлары:

| | | |
|---|---|---|
| Фәтхуллин А. Г. | - | Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |

Оештыру комитеты сәркатибе:

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин И. С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И. Х. | - | Район Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Галеев А.В. | - | Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Зарипов И. С. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Яхин Р. Р. | - | район Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Фәрхуллин И. Х. | - | «Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 134 янгын часте» ФДКУ башлыгы (килешү буенча); |
| Хәкимуллин Л. М. | - | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча МОНД башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Галиуллин И. И. | - | «Теләче үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Хуҗин Л. Й. | - | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» МҮ директоры (килешү буенча); |
| Карпова Н.В. | - | «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы; |
| Иксанов Д. С. | - | Район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Низаметдинов Р.Х. | - | Теләче районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин И. С. | - | Теләче муниципаль районының «БЯСМ» өстәмә белем бирү МБУ директоры; |
| Имамиев Т.Р. | - | Теләче муниципаль районының «БСББҮ» өстәмә белем бирү МБУ директоры; |
| Ибраһимов З. З. | - | «Олимп» ЯҮ МБУ директоры; |
| Сәйфетдинов Р.Р. | - | «Форпост» МБУ директоры; |
| Вәкаләтле вәкилләр | - | Россия көрәш федерациясе (килешү буенча); |
| Сабиров Ф.К. | - | «Теләче җылылык челтәрләре» МУП директоры; |
| Зиннәтуллин И. К. | - | «Мишә» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Мараков И. Р. | - | Теләче авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Шәйхетдинов А. Р. | - | «ХЭК» МБУ башлыгы. |